**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлегенең МордваИвановка торак пунктында гражданнар җыены карары**

2025елның 29 ноябре № 7

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлегенең Мордва Ивановка торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (25.11.2024 №1049 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлегенең Мордва Ивановкаторак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2026 елда Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлегенең Мордва Ивановка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, көндезге формада укучы студентлардан, срочная хәрби хезмәт узучы гражданнардан, свода катнашучылардан тыш, 3000,00 (Өч мең) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Мордва Ивановка авылында Ленин урамы, Совет урамы буенча урамнарны яктыртуга техник хезмәт күрсәтү);

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Мордва Ивановка авылында Ленин ур., Совет ур. буенча юллардагы чокырларны вак таш белән ремонтлау).

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: ТР, Лениногорск районы, Түбән Чыршылы авылы, Үзәк ур., 105 йорт адресы буенча урнашкан административ бинада, Совет ур., 8 йорт адресы буенча урнашкан балалар бакчасы бинасында, Тегермән ур., 23 йорт адресы буенча урнашкан ФАП бинасында. Мордва Ивановкаавылында-Тау ур., 27 йорт, Мордва Ивановка авылында-Совет ур., 13 йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) каббул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Лениногорск муниципаль районы
«Түбән Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Н.Я.Хәйруллина